| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ПОТАПОВО-ТУМБАРЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОТАПОВО-ТОМБАРЛЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.12. 2016ел. Потап-Тумбарлы № 34

Потап-Томбарлы
авыл җирлегенең 2017 елга
һәм 2018, 2019 елларның
планлы чорына бюджеты турында

Потап-Томбарлы авыл җирлеге Советы карары:

1 Статья 1. 1. Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджетының 2017 елга төп характеристикаларын расларга:

1) Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 8596,0 мең сум күләмендә;

2) Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 8596,0 мең сум.;

3) Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 мең сум.

2. 2018 елга һәм 2019 елга Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2018 елга Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 4782,9 мең сум һәм 2019 елга 4856,3 мең сум күләмендә;

2) 2018 елга Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 4782,9 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 118,0 мең сум күләмендә һәм 2019 елга 4856,3 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 239,0 мең сум күләмендә.;

3) Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 мең сум.

3. Потап-Томбарлы авыл җирлегенең 2017 елга һәм 2018, 2019 еллар план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга. 2 2 Статья 1. 2018 елның 1 гыйнварына Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.

4. 2017 елда Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджетының муниципаль бурычының иң чик күләмен 0 мең сум, 2018 елда-0 мең сум, 2019 елда-0 мең сум билгеләргә.

5 Статья 1. 5 нче кушымта нигезендә Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджетының 2017 елга һәм 2018, 2019 еллар план чорына чыгымнарының ведомство структурасын расларга.

6 Статья 1. Җирлек бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертларның күләмен раслау, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен 2017 елга 2122,0 мең сум күләмендә, 2018 елга 2223,0 мең сум күләмендә, 2019 елга 2223,0 мең сум күләмендә каралган.

7 Статья Баулы муниципаль районы бюджетыннан 2017 елда 9,9 мең сум күләмендә, 2018 елда 3269,0 мең сум күләмендә, 2019 елда 3320,4 мең сум күләмендә дотацияләр алына.

8 Статья Баулы муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына 2017 елда 2,4 мең сум, 2018 елда-2,2 мең сум, 2019 елда-2,2 мең сум күләмендә субвенцияләрне расларга.

9 Статья 2017 елда хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу өчен Баулы муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенцияләрне 2017 елда 81,7 мең сум, 2018 елда 81,7 мең сум, 2019 елда 81,7 мең сум күләмендә расларга.

10 Статья 1. Җирле үзидарә органнары 2017 елда муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмалары

хезмәткәрләре санын арттыруга, шулай ук аларны карап тотуга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

11 Статья Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджеты акчаларының 2016 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар Потап-Томбарлы авыл җирлеге башкарма комитеты исеменнән төзелгән килешүләр өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калган суммасыннан артмаган күләмдә калган өлеше 2017 елда Потап-Томбарлы авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә.

12 Статья Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Потап-Томбарлы авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

13 Статья 1. Әлеге карарны мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә һәм Потап-Томбарлы авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

2. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы А.М. Килячков